ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, ,
423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
N 1 03.11.2023

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын (бер тапкыр түләүләрне) кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләренә таянып,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамакм авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында"гы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 17 ноябрендә 9.00 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Бәйрәкәтамак авылы, Яңа урам, 36 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан; Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

-Бәйрәкәтамак торак пунктында зират территориясендәге койманы ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкәтамак торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы өчен МАФ сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru; Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча www.yutaza.tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә

«Бәйрәкәтамак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Ф.Г.Лукманов